Scientific Chronicles of the Turkic World
Төрки дөнья фәнни хроникасы
Научная хроника тюркского мира

# LATEST EVENTS IN 2015

On May 14-15, 2015, the delegation of the Institute of Philology and Intercultural Communications headed by Radif Zamaletdinov, Director of the Institute, took part in the International Symposium "The 190th Anniversary of Kayum Nasyri" in Ankara which was organized by TURKSOY and the Kayum Nasyri Institute at the Institute of Philology and Intercultural Communications, Kazan Federal University.

In his speech, Prof. R.R.Zamaletdinov described the structure of Kazan Federal University and the Institute of Philology and Intercultural Communications. He told the audience about the innovations in the University's education system, its research areas and growth prospects and its cultural and scientific collaboration with other world universities: its goals and objectives. R.R.Zamaletdinov also spoke about Kayum Nasyri as one of the founders of Tatar Studies, the purpose of organizing the Institute named after the great scholar at Kazan University, and the success in opening similar Institutes in well-known universities of Russia and foreign countries.

Prof. Alfiya Yusupova, head of the Department of Tatar Philology and Intercultural Communications named after G.Tukay, devoted her speech to Kayum Nasyri's great work on Tatar lexicology. Associate Prof. Gulnara Zamaletdinova described his pedagogical and methodological works, his study guides and their structure. Associate Prof. Tagir Gilyazov presented Kayum Nasyri as a folklore and literature expert and writer. Rasim Khusnutdinov, the director of Kayum Nasyri Institute, dealt with the theoretic and practical importance of the scholar's scientific and historical heritage for the Turkic World.

During the symposium proceedings, Ismet Binar, Professor of the world-known Istanbul University, devoted his speech to Kayum Nasyri's personality and his multifaceted activity in Turkish periodicals and literary collections. Ismail Turkogly, Associate Professor of Mimar Sinan Fine Arts University, demonstrated the socio-philosophical approach to the personality of Kayum Nasyri and highly appreciated his role in the Tatar World. Metin Demirdgy, Associate Prof. of Kahramanmarash University, made a speech "Kayym Nasyri in the Book by Gabdrahman Sagdi *Tatar Literature History*". The symposium was a step forward towards strengthening scientific and cultural relations between TURKSOY and the Institute of Philology and Intercultural Communications.

---

On May 18-19, 2015, the 2nd International Scientific and Educational Conference "*Bigievskie chteniya* (*'Bigiev Readings'*)" was held in Saint Petersburg. Its subject was: "Muslim Thinking in the 21st Century: Traditions and Innovations". The organizers of this conference were: the Central Muslim Spiritual Board of Russia, Russia Mufties Council, the Ministry of Religious Affairs of Turkey, the International Union of Muslim Scholars, the International University "Al-Mustafa", the State Hermitage Museum, Saint Petersburg State University, the Institute of Asian and African Studies of Lomonosov Moscow State Uni-

versity, the Institute of Oriental Studies of the Russian Academy of Sciences, Moscow Islamic University, the Foundation for Support of Islamic Culture, Science and Education, and media holding “Medina” with the participation of the Interreligious Council of Russia. The conference was attended by the heads of large Muslim organizations in Europe, philosophers and scholars from Russia, Belarus, Belgium, Great Britain, Germany, Iran, Qatar, Kuwait, Lithuania, Oman, Ukraine, Finland, and Estonia.

The issues of Muslim theological education and law development in the 20$^{th}$ century took centre stage. The conference was held in remembrance of Musa Bigiyev, the outstanding Tatar philosopher, theologian, publicist, and one of the jadidism leaders. The conference was opened by Rawil Gaynetdin, the Grand Mufti of Russia. In his welcome speech, Ilshat Gafurov, the Rector of Kazan Federal University, highlighted M. Bigiev’s role in Russian culture. The speakers at the plenary session were: Petr Petrovich Skorospelov, Director of the Culture Department of the Russian Government; Aleksey Alekseevich Zavarzin, Acting Rector of Saint Petersburg State University and Ali Muhiuddin Al-Qurra Daghi, Sheikh, Doctor and Secretary General of the International Union of Muslim Scholars.

On the second day of the Conference, Aidar Yuryevich Khabutdinov, Head of the Expert Board, Doctor of History, and Prof. Leylya Ildusovna Almazova, Candidate of Philosophy and head of the project team, presented the Resource Centre for Islamic Studies at the Institute of International Relations, History and Oriental Studies, Kazan Federal University, which was opened on March 26, 2015.

---

Turkestan is a city in the South Kazakhstan region which has long been playing an important role in the spiritual culture of the Turks. Until now, it has not lost its leading position in the life of the Turks. Here, the International University named after Ahmed Yasawi has been working since the 1990s and a variety of events have been held. One of them took place on May19-21, 2015. The International Conference "The Role and Importance of the Kazakh Khanate in the History of Kazakh Statehood" was organized in honour of the 550th anniversary of the Kazakh Khanate. About eight hundred scientists and writers took an active part in the conference; they were from Kazakhstan, Turkey, Azerbaijan, Iran, Russia, Uzbekistan, South Korea, Kyrgyzstan and other states. The reports discussed the issues of Turkic history, culture and literature. The plenary session was attended by Berdybek Saparbayev, the Deputy Prime Minister of the Republic of Kazakhstan, Aslan Sarinzhipov, the Minister of Education and Science of Kazakhstan, Arystanbek Muhamediuly, the Minister of Culture of the Republic of Kazakhstan and other prominent public figures. Hatip Minnegulov, Professor of Kazan Federal University, presented the report "The Artistic Realization of the Idea of Statehood in Turko-Tatar Literature", which aroused genuine interest of the audience.

A library of unique books and manuscripts in the Turkic language is being created at the initiative of Kulbek Ergobek, Director of the Institute of Turkic Studies at the International University named after Ahmed Yasawi. It accepts any books in the Turkic languages, dedicated to the Turkic world. [Address: 161200, Republic of Kazakhstan, Turkestan Str. Turgut Ozal, 10, the Library of Turkic Literature].

---

On May, 20-22, 2015, Kazakh State Women's Pedagogical University in Alma-Ata hosted the 2$^{nd}$ International Symposium on Turkic World Research. The proceedings were attended by over 500 participants from all five regions of Kazakhstan, the CIS countries, Turkey, the USA, China, Korea, the Netherlands, Serbia and other countries.

D.Zh.Nuketayeva, Rector of Kazakh State Women's Pedagogical University, opened the plenary session of the symposium. In her speech, the Rector referred to the origin of the symposium in the multifaceted Turkic world. The symposium was initiated by A .Görür, Rector of Niğde University. The project was implemented on the basis of the contract between Niğde University, Kazakh State Women's Pedagogical University, and Bashkir State Pedagogical University named after M.Akmulla. The first symposium was held last year at Niğde University, Turkey.

In Kazakhstan, the ancestral home of the Turkic peoples, nine main scientific areas received full consideration: the development and the future of classifications in the area of Turkic studies, the integration of education, relevant issues of Turkic philology, educational trends at the international level, the issues of the alphabet and gender in the Turkic World, etc. Also, the scientific symposium focused on the rela-

tionship between the history and heritage of the Kazakh Khanate and the fundamental idea of "Мәңгілік Ел (Eternal Country)".

The main objective of this large-scale scientific event was to research, develop, promote and update the cultural and spiritual values of the Turks.

The participants of the symposium were A.G.Gallyamova and A.Sh.Kabirova, Doctors of History, I.I.Hanipova, PhD in History, members of Sh.Mardzhani Institute of History at the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, and R.S.Nurmuhametova, PhD in Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication at Kazan Federal University.

---

On May 21-22, 2015 The International Scientific and Practical Conference "Rashit Rahmati Arat and the Turkic World" was held at the Institute of Philology and Intercultural Communication of Kazan Federal University. It was devoted to the 115th anniversary of R.R.Arat, the outstanding scholar and turcologist. It was organized in collaboration with the Kazan Centre named after Yunus Emre at the Institute of Turkish Studies.

At the opening ceremony, welcome speeches were given by Professor Radif Rifkatovich Zamaletdinov, Doctor of Philology and Director of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Turkhan Dilmach, Consul General of the Republic of Turkey in Kazan and Iksan Demirbash, Head of the Yunus Emre Centre at the Institute of Turkish Studies.

Professors from different universities in Turkey, Kazan scholars and R.R.Arat's fellow countrymen took part in the conference. They discussed R.R.Arat's research work, his role in the world of turcology, and the importance of his works for the Turkic languages.

The participants of the conference presented the following reports: Doctor Osman Fikri Sertkaya, Professor of Istanbul University and R.R.Arat's student, who continued his work as Director of the Institute of Turkic Studies at Istanbul University for 30 years − "Rashit Rahmati Arat: Life and Work"; Mirfatikh Zakiev, Doctor of Philology and Academician of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, − "Through Turkey to Turcology"; Mustafa Uner, Professor of Ege University in Turkey − "Comparative and Historical Philology and R.R.Arat"; Ozkan Oztekten, Associate Professor of the same university, − "Turkic Written Artifacts and R.R.Arat"; Enge Kadirova, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communications at KFU − "R.R.Arat's Role in Searching 'Kutadgu Belek'"; Milyausha Khafizova, Tatar language teacher from Staryj Uzyum in Atninsky District − "Rashit Rahmati Arat's Background in His Native Country".

The conference aroused great interest, many questions were asked and discussions were held. The scholars shared interesting ideas about the past, present and future of Turkology, and academic news.

On the second day of the Conference the participants went to R.Arat's native village Staryj Uzyum, where they met representatives of the regional authorities, the scholar's relatives, and school teachers.

---

On June 1, 2015 the Eurasian National University named after L.N.Gumilyov hosted the International Scientific Conference "Theoretical Issues of Literary Criticism and Rymgali Nurgaliyev's Research" in Astana. Prominent writers and scholars from Kazakhstan (N.Orazalin A.Kekilbayuly, S.Kaskabasov, S.Ibraev and E.Sydykov …), Russia and Turkey took part in it. At the plenary session of the conference, H.Minnegulov, Professor of Kazan Federal University, presented a report on "Kazakh-Tatar Literary Interactions" and shared his memories of R.Nurgaliyev; he also supervised the work of a section. On June 2, the Kazan scholar, together with Ali Cinar Abbas, a professor and poet from Turkey, spoke on the first channel of state television of the Republic of Kazakhstan.

---

From June 4 to 6, 2015 the International Scientific and Practical Conference "Historical and Archaeological Heritage of the Golden Horde in the Saratov Region: Ukek – Past, Present and Future" was held in Saratov. The conference was organized by: the Government of the Saratov region, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Saratov State University named after N.G.Chernyshevsky, the Saratov

Social and Economic Institute of the Russian Economic University named after G.V.Plekhanov and the NGO – Regional Tatar National and Cultural Autonomy of the Saratov Region.

On the first day, four sections held meetings: “The Material Culture of the Golden Horde in the Volga Region and Adjacent Territories”, "Cities of the Golden Horde in the Written Sources and Historiography”, “The Ethno-Cultural, Socio-Economic Development and Heritage of the Golden Horde" and "Cultural and Symbolic Ukek Heritage as a Humanitarian Resource of the Region”.

During the second day the plenary meeting discussed the results of the sectional work, which led to the adoption of a resolution. The Conference hosted about one hundred scientists from different countries: Russia, Kazakhstan, Mongolia, Finland, the USA and other countries. The participants of the conference discussed the issues related to the emergence of Ukek and its history, the results of archaeological excavations and other historical evidence. The resolution emphasized the historical value of Ukek and noted the importance of including the settlement of Ukek on the UNESCO list of World Heritage Sites.

*The information was submitted by A.Yusupova, Doctor of Philology, Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University; Minnegulov Kh., Doctor of Philology, Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University F.Nurieva, Doctor of Philology, Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University; E.Kadyrova, PhD in Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University, R.Nurmukhametova, PhD in Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University, and T.Gilazov PhD in Philology, Associate Professor of the Institute of Philology and Intercultural Communication, Kazan Federal University.*

# 2015 НЧЕ ЕЛДА БУЛГАН ВАКЫЙГАЛАР

2015 нче елның 14-15 нче май көннәрендә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов җитәкчелегендәге делегация Әнкара шәһәрендә ТЮРКСОЙ һәм КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршындагы Каюм Насыйри Институты тарафыннан оештырылган «Каюм Насыйриның тууына 190 ел» Халыкара симпозиумында катнашты.

Профессор Р.Р.Җамалетдинов үзенең чыгышында Казан федераль университеты, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының структурасы, уку-укыту системасындагы яңалыклар, гыйльми юнәлешләр, дөнья вузлары белән мәдәни һәм фәнни бәйләнешләр, үсеш перспективалары һәм алдагы бурычлар белән таныштырды. Р.Р.Җамалетдинов докладында Каюм Насыйри, татар халкын өйрәнү белемен нигезләүче галимнәрнең берсе буларак ачылып, Казан университетында аның исемендәге институтның оештырылу максаты, Россия һәм чит илләрнең танылган югары уку йортларында аны ачу юнәлешендәге нәтиҗәле адымнар хакында да мәгълүмат бирелде.

Г.Тукай исемендәге Татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге мөдире профессор Әлфия Юсупова энциклопедик галим К.Насыйриның татар тел белеменең лексикографиясе тармагындагы бай эшчәнлеге, доцент Гөлнара Җамалетдинова аның педагогик-методик хезмәтләре, ул әзерләгән уку-укыту әсбаплары, аларның төзелеш принциплары хакында гыйльми яктан тирән доклад ясадылар. Доцент Таһир Гыйлаҗев чыгышында К.Насыйри фольклор һәм әдәбият галиме, язучы буларак ачылды. Каюм Насыйри институты директоры Рәсим Хөснетдинов докладында галимнең фәнни һәм тарихи мирасының төрек дөньясында гыйльми һәм гамәли әһәмияте ассызыкланды.

Төркиянең дөньякүләм танылган Истанбул университеты галиме профессор Исмәт Бинәр докладында төрек матбугатында һәм әдәби җыентыкларында Каюм Насыйри шәхесе һәм күпьяклы эшчәнлегенең яктыртылышы бәян ителде. Мимар Синан Нәфис сәнгатьләр университеты доценты Исмаил Түркуглы, Каюм Насыйри шәхесенә иҗтимагый-фәлсәфи фикер яссылыгында якын килеп, аның татар галәмендә тоткан урынын һәм кыйммәтен бәяләде. Кахраман Мараш университеты доценты Метин Демирджи «Габдрахман Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» китабында Каюм Насыйри» докладлы белән чыгыш ясады. Симпозиум ТЮРКСОЙ Халыкара оешмасы белән Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты арасындагы гыйльми һәм мәдәни хезмәттәшлекне ныгытуда нәтиҗәле бер адым булды.

---

2015 нче елның 18-19 нчы маенда Санкт-Петербург шәһәрендә «XXI гасырда мөселман фикере: традицияләр берлеге һәм яңалыклар» темасына багышланган «Бигиев укулары» дигән II Халыкара фәнни-белем бирү конференциясе узды. Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте, Россия мөфтиләре советы, Төрек Республикасының дин эшләре министрлыгы, Мөселман галимнәренең бөтендөнья союзы, «Әл-Мостафа» Халыкара университеты, Дәүләт Эрмитажы, Санкт-Петербург дәүләт университеты, М.В.Ломоносов исемендәге Мәскәү дәүләт университетының Азия һәм Африка илләре институты, Россия Фәннәр академиясенең көнчыгыш телләрен өйрәнү институты, Мәскәү ислам институты, Ислам мәдәнияте, фәне һәм белем бирүгә ярдәм фонды, Россиянең Динара советы карамагындагы «Мәдинә» медиа-холдингы әлеге чараның оештыручылары булды. Конференциядә Европадагы зур мөселман оешмаларының җитәкчеләре, философлар һәм Россия, Белоруссия, Бельгия, Бөекбритания, Германия, Иран, Катар, Кувейт, Литва, Оман, Украина, Финляндия, Эстония галимнәре катнашты.

Форумда катнашучыларның игътибары үзәгендә XXI гасырда мөселман дин белеме һәм хокук үсеше мәсьәләләре булды. Конференция күренекле татар философы, дин белгече, публицист, җәдитчелек хәрәкәте лидерларыннан берсе Муса Бигиев истәлегенә үткәрелде. Конференцияне Россия мөфтиләр шурасы рәисе Равил Гәйнетдин ачты. КФУ ректоры Илшат Гафуров үзенең сәламләвендә М.Бигиевнең Россия мәдәниятенә керткән өлешен билгеләп үтте. Пленар утырышта Россия Федерациясе Хөкүмәтенең культура департаменты директоры Петр Петрович Скороспелов, Санкт-Петербург дәүләт университеты ректоры вазифаларын башкаручы Алексей Алексеевич

Заварзин, шәех, доктор, Мөселман галимнәренең бөтендөнья союзы генераль секретаре Али Мухиддин Аль-Карадагилар катнашты.

Конференциянең икенче көнендә Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институтында 2015 нче елның 26 нчы мартында ачылган ислам һәм исламны өйрәнү фәнен үстерүнең ресурс үзәген тәкъдим итү үтте. Презентацияне үзәкнең Эксперт советы рәисе тарих фәннәре докторы, профессор Айдар Юрьевич Хәбетдинов, проектны гамәлгә куюның эшче төркеме җитәкчесе философия фәннәре кандидаты, доцент Ләйлә Илдус кызы Алмазова үткәрде.

---

Көньяк Казахстанда урнашкан Төркестан – элек-электән төркиләрнең рухи тормышында мөһим роль уйнаган кала. Хәзер дә ул төрки дөньяда әһәмиятле урын били. Биредә узган гасырның 90нчы елларыннан бирле Әхмәд Ясәви исемендәге Халыкара казах-төрек университеты эшли, төрле чаралар уздырыла. Шундыйларның берсе 2015 нче елның 19-21 нче маенда булып үтте. Казах ханлыгы төзелүенә 550 ел тулуга багышланган «Казах дәүләтчелеге тарихында Казах ханлыгының роле һәм әһәмияте» дигән Халыкара фәнни-теоретик конференциядә Казахстан, Төркия, Әзербайҗан, Иран, Россия, Үзбәкстан, Көньяк Корея, Кыргызстан һәм кайбер башка илләрдән 800 ләп галим һәм әдип катнашты. Гыйлем әһелләре һәм әдипләрнең чыгышларында төркиләр тарихының, мәдәниятенең, әдәбиятының төрле яклары яктыртылды. Конференциядә Казахстан хөкүмәтенең премьер-министр урынбасары Бирдебәк Сапарбаев, белем һәм фән министры Аслан Сәринҗипов, мәдәният министры Арыстан Мөхәммәди улы һәм кайбер башка җитәкчеләр катнашты. Әлеге утырышта Казан федераль университеты профессоры Хатыйп Миңнегулов «Төрки-татар әдәбиятында дәүләтчелек идеясенең гәүдәләнеше» темасына доклад сөйләде.

Төркестанда Әхмәд Ясәви университетының Тюркология институты директоры, профессор Күлбәк Ергобәк инициативасы белән төрки телле басмаларны һәм кульязмаларны туплаган уникаль китапханә дә оешып килә. Ул төрки телле һәм төркигә мөнәсәбәтле һәртөрле китапларны кабул итәргә әзер. [Адресы: 161200, Республика Казахстан, город Туркестан, ул. Тургут Озал, д.10, Библиотека тюркоязычной литературы]

---

2015 нче елның 20-22 нче маенда Алматы шәһәренең Казах дәүләт хатын-кызлар педагогик университетында II Халыкара Төрки дөнья тикшеренүләре симпозиумы үткәрелде. Конференция утырышында Казахстан төбәкләре, БДБ илләреннән, Төркия, АКШ, Кытай, Корея, Нидерланд, Сербия һәм башка дәүләтләрдән 500 гә якын делегат катнашты.

Симпозиумның пленар утырышын Казах дәүләт хатын-кызлар педагогик университеты ректоры Д.Ж.Нукетаева ачып җибәрде. Ректор үзенең чыгышында киңкырлы төрки дөньяга багышланган әлеге симпозиумның үткәрелә башлаган вакытын, КазГосЖенПУ (Казах дәүләт хатын-кызлар педагогик университеты) һәм М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогик университеты килешүе нигезендә уртак проектны башлап җибәрүче Нигдә университеты ректоры А.Горурның керткән өлешен искәртеп узды. Беренче симпозиум узган ел Төркиядә Нигдә университетында уздырылган иде.

Төрки халыкларның борынгы Ватаны булган Казахстанда үткәрелгән II Халыкара Төрки дөнья тикшеренүләре симпозиумы төрки тел гыйлеме классификациясенең үсеше һәм киләчәге, белем бирү өлкәләренең интеграциясе, төрки филологиянең актуаль мәсьәләләре, алфавит проблемасы һәм төрки дөньяда гендерлык һ.б. фәнни юнәлешләрдә эш алып барды. Шулай ук фәнни симпозиум кысаларында Казах ханлыгы тарихы һәм мирасы бәйләнеше, «Мәңгілік Ел» фундаменталь идеясенә бәйле сораулар каралды.

Төркиләрнең мәдәни һәм рухи кыйммәтләрен өйрәнү, үстерү, популярлаштыру һәм яңарту киң масштаблы фәнни чараның төп максаты булып тора.

Симпозиум эшендә ТР Фәннәр академиясе Ш.Мәрҗани исемендәге тарих институты хезмәткәрләре тарих фәннәре докторлары А.Г.Галлямова һәм А.Ш.Кәбирова, тарих фәннәре

кандидаты И.И.Ханипова; Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, филология фәннәре кандидаты Р.С.Нурмөхәммәтова катнашты.

---

2015 нче елның 21-22 нче маенда Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында күренекле галим, тюрколог Р.Р.Аратның тууына 115 ел тулуга багышланган «Рәшит Рәхмәти Арат һәм төрки дөнья» дип аталган Халыкара фәнни-гамәли конференция үтте. Бу чара Юныс Эмре исемендәге Төркияне өйрәнү институтының Казандагы үзәге белән бергә оештырылды.

Конференциянең тантаналы ачылыш утырышында Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры, филология фәннәре докторы, профессор Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов, Төркия Республикасының Казан шәһәрендәге Генераль консулы Турхан Дильмач, Юныс Эмре исемендәге Төркияне өйрәнү институтының Казандагы үзәге җитәкчесе Ихсан Демирбаш сәламләү сүзе белән чыгыш ясадылар.

Конференциядә Төркиянең төрле университетларыннан килгән профессорлар, Казан галимнәре, Р.Р.Аратның якташлары катнашты. Алар Р.Р.Аратның фәнни эшчәнлеген, дөньякүләм тюркологиядәге урынын, хезмәтләренең төрки телләр өчен әһәмиятен бәян иттеләр.

Истанбул университеты профессоры, Р.Р.Аратның шәкерте, соңыннан 30 еллап аның эшен Истанбул университетының Төркият институты директоры буларак дәвам иткән профессор, доктор Осман Фикри Серткая «Рәшит Рәхмәти Арат: тормыш юлы һәм эшчәнлеге», ТР Фәннәр академиясенең академигы, филология фәннәре докторы Мирфатыйх Зәкиев «Төркия аша тюркологиягә», Төркиянең Эгей университеты профессоры Мостафа Өнәр «Чагыштырма-тарихи филология һәм Р.Р.Арат», шул ук университет доценты Озкан Өзтектен «Төрки телле язма истәлекләр һәм Р.Р.Арат», КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты Энҗе Кадыйрова «Р.Р.Аратның «Котадгу белек» әсәрен өйрәнүгә керткән өлеше», Әтнә районы Иске Әҗем мәктәбенең татар теле укытучысы Миләүшә Хафизова «Рәшит Рәхмәти Аратның туган илдәге тамырлары» дигән темаларга бик кызыклы докладлар сөйләделәр.

Конференция тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты, чыгыш ясаучыларга сораулар күп булды, фикер алышулар оештырылды. Галимнәр тюркологиянең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәгенә караган кызыклы карашлар, фәнни яңалыклар белән уртаклаштылар.

Конференциянең икенче көнендә анда катнашучылар, Р.Аратның туган авылы – Иске Әҗемгә кайтып, район хакимиятенең җитәкчелеге, галимнең туганннары һәм мәктәп укучылары белән очраштылар.

---

2015 нче елның 1 нче июнендә Астана каласындагы Л.Н.Гумилев исемендәге Евразия Милли университетында «Әдәбият фәненең теоретик мәсьәләләре һәм академик Рымгали Нургалиев тикшеренүләре» темасына багышланган Халыкара фәнни-теоретик конференция булып узды. Аның эшендә Казахстанның Н.Оразалин, Ә.Кекилбайулы, С.Каскабасов, Е.Сыдыков кебек күренекле әдипләре, галимнәре, шулай ук парламент депутатлары, хөкүмәт вәкилләре катнашты. Казан федераль университеты профессоры Хатыйп Миңнегулов конференциянең пленар утырышында «Казах-татар әдәби бәйләнешләре» темасына доклад сөйләде һәм күренекле галим, әдәбиятчы, язучы Рымгали Нургалиев (1940-2010) турындагы истәлекләре белән уртаклашты, шулай ук секция белән дә җитәкчелек итте.

2 нче июньдә Х.Миңнегулов, Төркия профессоры, шагыйрь Али Аббас Чинар белән берлектә, Казахстан дәүләт телевидениесенең беренче каналында конференция тематикасы буенча туры эфирда чыгыш ясады, куелган сорауларга җаваплар бирде.

---

2015 нче елның 4-6 нче июнендә Саратовта «Саратов өлкәсендә Алтын Урданың тарихи-археологик мирасы: Укек – үткәне, хәзергесе, киләчәге» дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция булып узды. Бу конференция Саратов өлкәсе хөкүмәте, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Н.Г.Чернышевский исемендәге Саратов дәүләт университеты, Г.В.Плеханов

исемендәге Россия икътисад университетының Саратов социаль-икътисад институты, Саратов өлкәсенең Татар милли-мәдәни төбәк автономия иҗтимагый оешмасы тарафыннан оештырылды.

Конференциянең беренче көнендә 4 секция эшләде: «Идел буенда һәм аның белән чиктәш территорияләрдә Алтын Урданың матди мәдәнияте», «Язма чыганакларда һәм историографиядә Алтын Урда шәһәрләре», «Алтын Урданың этномәдәни һәм социаль-мәдәни үсеше һәм мирасы», «Төбәкнең гуманитар ресурсы буларак, Укекның мәдәни-символик мирасы».

Икенче көнне пленар утырышта секция эшләренә нәтиҗәләр ясалды һәм резолюция кабул ителде. Конференциядә Россия, Казахстан, Монголия, Финляндия, АКШ һ.б. илләрдән 100 гә якын галим катнашты. Фәнни-гамәли конференциядә Укек шәһәренең барлыкка килүе һәм аның тарихына бәйле сораулар каралды, археологик казу эшләре нәтиҗәләре һәм башка тарихи белешмәләр хакында фикер алышынды. Резолюциядә Укекның тарихи кыйммәте ассызыкланды һәм шулай ук Укек шәһәрчеген ЮНЕСКО объектлары исемлегенә кертүнең әһәмияте искәртелде.

*Материалларны Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры, филология фәннәре докторы Ә.Ш.Юсупова, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры, филология фәннәре докторы Х.Ю.Миңнегулов, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры, филология фәннәре докторы Ф.Ш.Нуриева, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, филология фәннәре кандидаты Э.Х.Кадыйрова, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, филология фәннәре кандидаты Р.С.Нурмөхәммәтова, Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты доценты, филология фәннәре кандидаты Т.Ш.Гыйлаҗев әзерләде.*

# ПРОШЕДШИЕ СОБЫТИЯ 2015 ГОДА

14-15 мая 2015 года делегация под руководством директора Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета Радифа Замалетдинова участвовала в международном симпозиуме «190 лет со дня рождения Каюма Насыри», организованном Институтом имени Каюма Насыри.

В своем выступлении профессор Р.Р.Замалетдинов ознакомил слушателей со структурой Казанского федерального университета, Института филологии и межкультурной коммуникации, с новостями в системе обучения, с научными направлениями, культурными и научными связями с вузами с мировым именем, перспективами роста и предстоящими задачами. В своем докладе он отметил, что К.Насыри раскрылся как один из исследователей, основавших учение о татарском народе, о целях образования Института имени Каюма Насыри при Казанском университете.

Заведующий отделением татарской филологии и истории имени Г.Тукая профессор А.Ш.Юсупова выступила с докладом о разносторонней деятельности ученого-энциклопедиста К.Насыри в области татарской лексикографии, доцент Гульнара Замалетдинова рассказала о педагогико-методических трудах К.Насыри, о его учебниках, о принципах их построения. Доцент Тагир Гилазев рассказал о Насыри как о знатоке фольклора и литературы, писателе. В докладе директора института имени Каюма Насыри Расима Хуснутдинова была подчеркнута научная и практическая важность наследия ученого в турецком мире.

Во время работы симпозиума был представлен доклад профессора Университета Стамбула Исмата Бинара о личности К.Насыри и его разносторонней публикационной деятельности в турецких изданиях и литературных сборниках. Исмаил Тюркоглу, доцент Университета художественных искусств Мимара Синана, подойдя к личности Каюма Насыри в социально-философском смысловом аспекте, оценил его место и ценность в татарском мире. Доцент Университета Кахрамана Мараша Метин Демирджи выступил с докладом о К.Насыри в книге Абдрахмана Саади «История татарской литературы». Симпозиум стал результативным шагом в деле укрепления научного и культурного сотрудничества между Тюркской международной организацией и Институтом филологии и межкультурной коммуникации.

---

18-19 мая 2015 года в Санкт-Петербурге прошла II Международная научно-образовательная конференция «Бигиевские чтения», посвященная теме «Мусульманская мысль в XXI веке: единство традиции и обновления». Организаторами данного мероприятия выступили Духовное управление мусульман Российской Федерации, Совет муфтиев России, Министерство по делам религии Турецкой Республики, Всемирный Союз мусульманских ученых, Международный университет «Аль-Мустафа», Государственный Эрмитаж, Санкт-Петербургский государственный университет, Институт стран Азии и Африки Московского государственного университета имени М.В.Ломоносова, Институт востоковедения Российской академии наук, Московский исламский институт, Фонд поддержки исламской культуры, науки и образования, медиа-холдинг «Медина» при поддержке Межрелигиозного совета России. В конференции приняли участие главы крупнейших мусульманских объединений Европы, философы и ученые из России, Белоруссии, Бельгии, Великобритании, Германии, Ирана, Катара, Кувейта, Литвы, Омана, Украины, Финляндии, Эстонии.

В центре обсуждения участников форума – развитие мусульманской богословской и правовой мысли в XXI веке. Конференцию, которая проводится в память о Мусе Бигиеве, выдающемся татарском философе-богослове, публицисте, одном из лидеров джадидизма, открыл председатель Совета муфтиев России Равиль Гайнутдин. В своем приветствии ректор КФУ Ильшат Гафуров отметил особый вклад М.Бигиева в российскую культуру. В работе пленарного заседания приняли участие директор Департамента культуры Правительства Российской Федерации Петр Петрович Скороспелов, и.о. ректора Санкт-Петербургского государственного университета Алексей Алексеевич Заварзин, а также Али Мухиддин Аль-Карадаги – шейх, доктор, Генеральный секретарь Всемирного союза мусульманских ученых.

19 мая на конференции прошла презентация Ресурсного центра по развитию исламского и исламоведческого образования при ИМОИиВ КФУ, открытого 26 марта 2015 г. Презентацию прове-

ли председатель Экспертного совета центра, доктор исторических наук, профессор Айдар Юрьевич Хабутдинов, руководитель рабочей группы по реализации проекта кандидат философских наук, доцент Лейла Ильдусовна Алмазова.

---

Туркестан – город в Южно-Казахстанской области, издавна играющий важную роль в духовной культуре тюркских народов. И поныне он не утратил своего лидирующего положения в жизни тюрок. Здесь с 1990-х годов функционирует Международный университет имени Ахмеда Ясави, проводятся различные мероприятия. Одно из них состоялось 19-21 мая 2015 года: на Международной конференции «Роль и значение Казахского ханства в истории Казахской государственности», организованной в честь 550-летия Казахского ханства, приняли активное участие около 800 ученых и писателей из Казахстана, Турции, Азербайджана, Ирана, России, Узбекистана, Южной Кореи, Киргизии и других государств. В научных докладах нашли освещение вопросы тюркской истории, культуры, литературы. В Пленарном заседании приняли участие заместитель премьер-министра Республики Казахстан Бердибек Сапарбаев, министр образования и науки Республики Казахстан Аслан Саринжипов, министр культуры Республики Казахстан Арыстанбек Мухамедиулы и другие видные государственные деятели. Доклад профессора Казанского федерального университета Хатипа Миннегулова «Художественное воплощение идеи государственности в тюрко-татарской литературе» вызвал у собравшихся неподдельный интерес.

По инициативе директора Института тюркологии Международного университета имени Ахмеда Ясави Кулбека Ергобека формируется библиотека уникальных изданий и рукописей на тюркском языке. Она готова принять любые книги на тюркских языках, посвященные тюркскому миру. [Адрес: 161200, Республика Казахстан, город Туркестан, ул.Тургут Озал, д.10, Библиотека тюркоязычной литературы].

---

20-22 мая 2015 года в Казахском государственном женском педагогическом университете г. Алматы проходил II Международный симпозиум исследований тюркского мира. В заседании мирового уровня приняли участие более 500 делегатов со всех регионов Казахстана, стран СНГ, Турции, США, Китая, Кореи, Нидерландов, Сербии и других государств.

Пленарное заседание симпозиума открыла ректор Казахского государственного женского педагогического университета Д.Ж.Нукетаева. В своем выступлении ректор упомянула о зарождении данного симпозиума, посвященного многогранному тюркскому миру, о вкладе ректора университета Нийде А.Горура, который положил начало совместному проекту на основе контракта университета Нийде, КазГосЖенПУ и Башкирского государственного педагогического университета имени М.Акмуллы. Первый симпозиум был проведен в прошлом году в стенах университета Нийде Турции.

На II Международном симпозиуме исследований тюркского мира, который проходил в Казахстане – прародине тюркских народов, осуществлялась работа по следующим научным направлениям: развитие и будущее классификаций тюрковедения, интеграция образования, актуальные проблемы тюркской филологии, образовательные направления на международном уровне, проблемы алфавита и гендера в тюркском мире и т.д. Также в рамках научного симпозиума были обсуждены вопросы, касающиеся взаимосвязи истории и наследия Казахского ханства и фундаментальной идеи «Мәңгілік Ел».

Главная задача столь масштабного научного мероприятия заключается в исследовании, развитии, популяризации и обновлении культурных и духовных ценностей тюрков.

В работе данного симпозиума приняли участие сотрудники Института истории имени Ш.Марджани Академии Наук РТ доктора исторических наук А.Г.Галлямова и А.Ш.Кабирова, кандидат исторических наук И.И.Ханипова; доцент Института филологии и межкультурной коммуникации КФУ, кандидат филологических наук Р.С.Нурмухаметова.

---

21-22 мая 2015 года в Институте филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета прошла научно-практическая конференция «Рашит Рахмати Арат и тюркский мир», посвященная 115-летию со дня рождения видного ученого, тюрколога Р.Р.Арата. Это мероприятие было проведено совместно с Казанским центром Института изучения Турции.

На торжественном открытии заседания конференции с приветственными речами выступили директор Института филологии и межкультурной коммуникации, доктор филологических наук, профессор Замалетдинов Радиф Рифкатович, Генеральный консул Турецкой Республики в городе Казани Турхан Дильмач, заведующий казанским центром Института изучения Турции имени Юнуса Эмре Исхан Демирбаш.

На конференции выступили профессора различных университетов Турции, казанские ученые, земляки Р.Р.Арата. Профессор Университета Стамбула, ученик Р.Р.Арата, продолживший деятельность ученого в качестве директора института Туркият Университета Стамбула доктор Осман Фикри Серткая в докладе «Рашит Рахмати Арат: жизненный путь и деятельность», академик Академии наук РТ, доктор филологических наук Мирфатих Закиев в докладе «К тюркологии через Турцию», профессор Эгейского университета Турции Мустафа Онер в докладе «Сравнительно-историческая филология и Р.Р.Арат», доцент того же университета Озкан Озтектек в своем выступлении «Тюркоязычные письменные памятники и Р.Р.Арат», доцент Института филологии и межкультурной коммуникации КФУ Энже Кадирова в докладе «Вклад Р.Р.Арата в изучение памятника «Кутадгу билиг», а также учитель татарского языка школы в Старом Ажиме Атнинского района Миляуша Хафизова в выступлении «Корни Рашита Рахмати Арата в родной стране» рассказали о научной деятельности, о роли ученого в мировой тюркологии, о важности его трудов для тюркских языков.

Конференция вызвала живой интерес у слушателей. Прозвучали интересные мысли, научные новости из мира прошлого, настоящего и будущего тюркологии.

На второй день конференции участники посетили родную деревню Арата – Старый Узюм, встретились с руководством Арского района, родственниками Арата и учениками сельской школы.

---

1 июня 2015 года в Евразийском национальном университете имени Л.Н.Гумилева (г.Астана) состоялась Международная научно-теоретическая конференция «Теоретические проблемы литературоведения и исследования Р.Нургали». В ее работе принимали известные писатели, ученые Казахстана (Н.Оразалин, А.Кекильбайулы, С.Каскабасов, Ш.Ибраев, Е.Сыдыков и др.), России, Турции. Рымгали Нургалиев (1940-2010) – крупный ученый, педагог, организатор науки, писатель. Профессор Казанского федерального университета Х.Миннегулов на пленарном заседании конференции выступил с докладом «О казахско-татарских литературных взаимосвязях», поделился воспоминаниями о Р.Нургалиеве, а также руководил секцией. На следующий день, 2 июня, казанский ученый выступил по первому каналу государственного телевидения Республики Казахстан совместно с профессором и поэтом из Турции Али Аббасом Чинаром.

---

4-6 июня 2015 года в Саратове состоялась Международная научно-практическая конференция «Историко-археологическое наследие Золотой Орды на территории Саратовской области: Укек – прошлое, настоящее, будущее». Организаторами конференции выступили Правительство Саратовской области, Академия наук Республики Татарстан, Саратовский государственный университет имени Н.Г.Чернышевского, Саратовский социально-экономический институт Российского экономического университета имени Г.В.Плеханова, общественная организация – Региональная татарская национально-культурная автономия Саратовской области.

В первый день состоялась работа 4-х секций: «Материальная культура Золотой Орды в Поволжье и сопредельных территориях», «Города Золотой Орды в письменных источниках и историографии», «Этнокультурное и социально-экономическое развитие и наследие Золотой Орды», «Культурно-символическое наследие Укека как гуманитарный ресурс региона».

Во второй день состоялось пленарное заседание, на котором обсуждались итоги секционных работ, по результатам которых была принята резолюция. В работе научно-практической конференции приняли участие около 100 ученых из разных стран: России, Казахстана, Монголии, Финляндии, США и др. Участники конференции обсуждали вопросы, связанные с возникновением Укека и его историей, также были рассмотрены итоги археологических раскопок, другие исторические свидетельства. В резолюции подчеркнута историческая ценность Укека, а также была отмечена значимость внесения Укекского городища в список объектов ЮНЕСКО.

*Материалы подготовлены А.Ш.Юсуповой, доктором филологических наук, профессором Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета; Х.Ю.Миннегуловым, доктором филологических наук, профессором Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета; Ф.Ш.Нуриевой, доктором филологических наук, профессором Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета; Э.Х.Кадировой, кандидатом филологических наук, доцентом Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета; Р.С.Нурмухаметовой, кандидатом филологических наук, доцентом Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета; Т.Ш.Гилазовым, кандидатом филологических наук, доцентом Института филологии и межкультурной коммуникации Казанского федерального университета.*